ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» декабрь 2019 ел. № 472

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
"2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында
мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын
тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында
балаларны карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең
уртача күләмен раслау турында" 2019 ел, 28 ноябрь, 457нче карарын,
“2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында
мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын
гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында
һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә,
башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем,
шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның
дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау
турында" 2019 ел, 28 ноябрь, 459нчы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлдән чыгарырга:
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны карап тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең уртача күләмен раслау турында" 2019 ел, 28 ноябрь, 457нче карарын;
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының “2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында" 2019 ел, 28 ноябрь, 459нчы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес

буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.С. Авдеев**